ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЙНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
МАЙНА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Югары Тат.Майнасы ав.

**28.01.2021** **№ 1**

**Мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

**карар кылам:**

1. Кушымта нигезендә Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлегендә 6424,98 сум күләмендә 2021 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү һәм гамәлгә кертү.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 ел 29 нчы гыйнварының 54 нче номерлы “Мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантяләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында”гы карарын көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталындагы җирлек сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге советы бинасында махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районының**
**Майна авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Н.Гафиятуллин**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 ел 28 нчы гыйнварының 1 нче номерлы карарына кушымта

**Мәет җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 2021 елның 1 февраленнән**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2441,84 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка китерү | 920,0 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3063,14 |
| Барлыгы | 6424,98 |

**Мәет җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 2021 елның 1 февраленнән**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Кәфенләү | 394,00 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2047,84 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка китерү | 920,00 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3063,14 |
| Барлыгы | 6424,98 |